Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Детский сад общеразвивающего вида №6» «Жемчужинка» Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе “6 нчы номерлы гомум үсеш төрендәге «Жемчужинка» балалар бакчасы

Утверждено и введено в действие
приказом № 153 от 28.08.2024 г.
Заведующий МБДОУ «Детский сад № 6»
_________О.Р.Захарова

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 0087A0B217414A40FE0BE3A1474CAE00E3
Владелец: Захарова Ольга Рудольфовна
Действителен: с 28.12.2023 до 22.03.2025

# 2024-2026 уку елына
# 6 нче номерлы “Семицветик” исемле төркемендә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру буенча календарь перспектив планлаштыру

*мәктәпкәчә 5-7 яшьтәге балалар өчен*

Рассмотрено и принято
на заседании педсовета
протокол № 1 от 28.08.2024 г.

**Татар теле тәрбиячесе Закирова Г.И.**

## Аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

## Зурлар төркеме (5 – 6 яшь)

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1.Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;

2.Тел системасының фонетик, лексик,грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;

3.Бәйләнешле сөйләм үстерү.

4.Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

5.Ана телендә аралашырга теләк уяту; үз гаиләң, әти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

Укыту-методик комплектларга тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү,тирә-юнь,матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру мак-сатында гына түгел,ә рәсем ясау,әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү,эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү,саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.

“Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын,байлыгын аңларга,аны сиземләргә,үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга,тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә,туган телебезгә мәхәббәт, әти- әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт итәгать тәрбияләү, үзлә-рендә хезмәт сөю, тыйнаклык,шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә. Балалар “сүз”, “аваз” терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Ирешелгән нәтиҗәләр: Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә белә.Предмет һәм аның үзенчәлекләре,нинди материалдан булуы турында сөйли, аларны төркемли белә.Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә.Бала үз туганнары,үзе турында сөйли,адресын әйтә белә.Туган иле, шәһәре, Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә.Сөйләмдә, башка балалар белән аралашканда ягымлы сүләр куллана белә Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтә белә Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи белә.Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә,рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша ,тиз истә калдырып, яттан сөйли белә.

**Мәктәпкәчә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары

1. Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
2. Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
3. Бәйләнешле сөйләм үстерү;
4. Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге**

Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педгогларына балаларның сөйләмен үстерү,тирә-юнь,матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру мак-сатында гына түгел,ә рәсем ясау,әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү,эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү,саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.

“Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын,байлыгын аңларга,аны сиземләргә,үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга,тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә,туган телебезгә мәхәббәт, әти- әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт итәгать тәрбияләү, үзлә-рендә хезмәт сөю, тыйнаклык,шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балалар “сүз”, “аваз” терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

**Ирешелгән нәтиҗәләр:(безне нәрсә шатландыра)**

Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый.Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмәт бирә ала.Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә.Үзенең адресын, телефон номерын әйтә белә.Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша. Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен аңлап, төгәл куллана ала. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча иҗади хикәя төзи белә.Әсәрнең жанрын билгели ала.(әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларына карата үз мөнәсәбәтен белдерә ала. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли.Китаплардан я;а белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**“Туган телдә сөйләшәбез” комплекслы тематик планы**
**(икенче вариант)**
**<u>Зурлар төркеме 5-6 яшь</u>**

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны | Сүзлек |
|---|---|---|---|
| 1. «Яхшы сүз-җан азыгы» | Танышу<br>Ягымлы сүзләр<br>Сыйла(катнаш эшчәнлек) | 1<br>1<br>1 | Исәнмесез,<br>Саубулыгыз<br>Рәхмәт<br>Әйбәт<br>Тәмле /тәмсез/телле |
| 2. А. Алиш иҗаты | А.Алиш- балалар язучысы.<br>А.Алиш “Каз белән аккош” | 1<br>1 | Батыр,көрәшче,<br>Әләкче<br>Аккош,ябык,көчсез<br>таза |
| | «Чукмар белән Тукмар» (катнаш эшчәнлек) | 1 | Әтәч, |
| 3. Хуш киләсең, ямьле көз! | Җәйләр үтте, көзләр җитте.<br>Көзге табигать | 1<br>1 | Көз,сары,сап-сары,яшел,ямҗ-яшел, |
| | “Шалкан” (катнаш эшчәнлек) | 1 | Әби,бабай,кыз,эт,песи,<br>тычкан |
| 4. Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт<br>Сыйлыйбыз | 1<br>1 | Чүлмәк,яшелчә,кыяр<br>Бәрәңге,кәбестә,суган,күп,бер |
| | “Баллы кишер” (катнаш эшчәнлек) | 1 | Кишер.баллы.тәмле. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Түтәлләрдә үсте яшелчә<br>Яшелчәләр кибете<br>Бар матур бакча | 1<br>1 | Яшелчә.кибет.бакча |
| 5. Мин яратам сине, Татарстан | Мин яратам сине, Татарстан<br>Туган җирем- Татарстан | 1<br>1 | Чишмә.балачак.яратам<br>Туган җир |
| | “Уйный-уйный эшлибез” | 1 | эшли |
| | Гүзәл туган ягыбыз<br>Туган ил кайдан башлана? | 1<br>1 | Гүзәл.<br>балачак. |
| | Мультфильм “Акбарс” | 1 | Акбарс |
| 6. Төсләр дөньясы | Төсләр<br>Төсләр дөньясы | 1<br>1 | Ак,кара,кызыл,сары,яшел,зәңгәр |
| | “Юл мажаралары”. | 1 | Ак,кара,кызыл,сары,яшел,зәңгәр |
| 7. Кем эшләми , шул ашамый. | Яшелчә салаты<br>Яшелчәләр юабыз. | 1<br>1 | Кәбестә,суган,кыяр,бәрәңге,шалкан,кишер |
| | “Кем эшләми, шул ашамый” | 1 | |
| 8. Җиләк-җимешләр | Җимешләр<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Җиләк-җимешләр | 1<br>1<br>1 | Алма,җиләк,әфлисун, |
| 9. Минем гаиләм | Безнең гаилә<br>Әби , бабайларны хөрмәтлик. | 1<br>1 | Әти,әни,әби,бабай,кыз,малай |
| | “Аш бүлмәсе” | 1 | |
| 10. Табын янында | Савыт-саба кибетенә сәяхәт.<br>Савыт-саба.<br>Бергәләп өйрәнәбез.<br>Курчак Алиягә булыш<br>Чәй табыны | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 | Чынаяк.чәнечке.пычак.<br><br>Чәйнек.кашык.сатучы.<br><br>Кәстрүл.сатып алучы.киштә |
| | “Өч аю” . | 1 | |
| 11. Киемнәр дә безне бизиләр | Кием кешене бизи<br>Кием - салым кибетенә сәяхәт | 1<br>1 | Бизи.шәл.бүрек.башлык.өс.аяк киемнәре. |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 | |
| 12. Салкын кыш. Кышкы уеннар. | Салкын кыш<br>Кышкы уеннар | 1<br>2 | Кыш.кар.ап-ак.шуам.салкын<br>Шук.шаян.тимераяк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | К.Ушинский“ Кыш әбинең шуклыгы.” | 1 | Җанвар,корт |
| | Без суыктан курыкмыйбыз. | 2 | Алсу,шуам |
| | Кышкы уеннар<br>Ел фасыллары | 2<br>1 | Шук.шаян.тимераяк<br>Кыш,көз,яз,җәй |
| | Куян кызы | 1 | |
| 13. Кунак булсаң-тыйнак бул | Савыт-саба<br>Мин кунак яратам<br>Бергәләп өйрәнәбез | 1<br>1<br>1 | Чынаяк,чәйнек,кәстрүл,кашык,тәлинкә,чәнечке<br>Милли ризыклар<br>Чынаяк,чәйнек,кәстрүл,кашык,тәлинкә,чәнечке |
| 14. Киемнәр | Киенергә ярдәм ит<br>Милли киемнәр. | 1<br>1 | <br>Калфак.түбәтәй.алъяпкыч. |
| | “Киемнәр кибетендә” | 1 | |
| | Киемнәр дә безне бизиләр.<br>Киемнәр дөньясы | 1<br>1 | Бүрек,шәл,башлык |
| | ”Ни өчен киемнәр югалган” | 1 | Чиста,пычрак |
| 15. Йорт җиһазлары | Матур әдәбият белән таныштыру өстәл театры “Өч аю”.<br>Өй җиһазлары кибете. | 1<br>1 | Өстәл,урындык,карават |
| | “Маша һәм өч аю” | 1 | |
| 16. Йорт хайваннары һәм кошлары | “Ишегалдында” хикәя төзү<br>“Песи 1әм песи балалары” рәсеме | 1<br>1 | Песи,эт,сыер,сарык,кәҗә,тавык,чеби,каз,дуңгыз ,үрдәк,ат,әтәч<br>Песи балалары,йомшак |
| | Г.Мөхәммәтшин“Ак песи”. | 1 | абый |
| 17. Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа | Без әни белән кибеткә бардык | 2 | Әни.тегүче.пешекче.шәфкать туташы,тәрбияче |
| | “Өч кыз”әкияте | 1 | |
| | Әниемнең тәмле ашлары | 2 | Милли ризыклар |
| | “Әни гөлләре” | 1 | Гөл,кулъяулык |
| 18. Без язны яратабыз | Яз килә. | 2 | Яз.җил.гөрләвек.ләйсән яңгыр |
| | “Кем нәрсә ярата?”. | 1 | |
| | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Нәүрүз – яз бәйрәме | 2<br>1 | Кояш |
| 19. Безнең канатлы дусларыбыз | Күчмә кошлар<br>Кошлар | 1<br>1 | Сыерчык.сыерчык оясы.карга<br>Карлыгач.чыпчык.сандугач. тукран |
| | “Карлыгач” Г.Тукай | 1 | Тәрәзә,балчык |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20. Габдулла Тукай иҗаты | Габдулла Тукай<br>Г. Тукайның “Кызыклы шәкерт” шигыре | 1<br>1 | Туган тел.<br>Кызыклы шәкерт.эт. |
| | Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнардан өзекләр карау. | 1 | |
| | Г. Тукай “Безнең гаилә”<br>“Гаилә” рәсемен карау | 1<br>1 | Гаилә темасына кергән лексика |
| | Г. Тукай “Бала белән күбәләк” | 1 | Бала.күбәләк.оча. |
| 21. Чисталыкта-матурлык | Саулык-зур байлык<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй “Чисталык сөябез” | 1<br>1 | <br>пөхтә |
| | “Куян кызы” әкияте | 1 | Киез-итек,сәламәтлек,яланаяк |
| 22. Җиңү алып килде май | Сугыш ветераннары белән очрашу | 1 | Җиңү.хәтер.батыр.бөек ватан сугышы. |
| 23. Заманча әкиятләр | “Винни-пух кунакка бара”.<br>“Чебурашка” | 2 | |
| 24. Хәрәкәттә-бәрәкәт | Минем яраткан спорт төре.<br>Шигырь уку: В Хәйруллина “Туплар” | 1<br>1 | Көрәш.милли.көрәшче<br>сикергеч |
| | Спорт мәйданчыгында” | 1 | |
| 25. Чәчәкле җәй. | Чәчәкләр – тормыш яме<br>Чәчәкле җәй. | 1<br>1 | Энҗе чәчәк,ак чәчәк,умырзая<br>Җәй.чәчәк.җылы.кояш |
| | Сабантуй бәйрәме | 1 | Көрәш.милли.уен. |
| 26. Күңелле сабантуй | Күңелле Сабантуй уеннары<br>Сабан туена әзерлек | 1<br>2 | Милли уеннар |
| | | 102 | |

**Туган телдә сөйләшәбез (икенче вариант)**
**Комплекслы тематик план**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме  6-7 яшь**

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны | Сүзлек |
|---|---|---|---|
| 1. Әйдәгез,танышабыз! | Әйдәгез, танышабыз<br>Тәмле сүз – җан азыгы | 1<br>1 | Исәнмесез,саубулыгыз,рәхмәт<br>Тәмле сүз |
| | “Мияу адашкан” | 1 | |
| 2. Тату гаилә | Минем өем<br>Тату гаилә | 1<br>1 | Әти,әни,әби,бабай,кыз,малай |
| | “Аю баласы дөнья белән таныша” | 1 | |
| 3. Абдулла Алиш иҗаты | А. Алиш иҗаты белән танышу.<br>А.Алиш “Сертотмас үрдәк” әкияте | 1<br>1 | Үрдәк.койрыклар. |
| | «Батыр Мияу белән куркак Куянкай» | 1 | Батыр.куркак |
| 4. Алтын көз | Алтын көз<br>Көз җитте | 1<br>1 | Көз.яфрак.агач. |
| | “Шалкан” | 1 | |
| 5. Көзге байлык | Яшелчәләр | 2 | Уңыш. |
| | «Кем эшләми, шул ашамый.” | 1 | |
| 6. Көз күчтәнәчләре | Җиләк-җимешләр<br>Көз күчтәнәчләре | 1<br>1 | Алма,җиләк,әфлисун,<br>Суган.бәрәңге.шалкан.кишер,борыч.кабак |
| | “Дәү әнием -бакчачы”Х.Халиков | 2 | Дәү әни,бакчачы |
| 7. Икмәк – яшәү терәге | “Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә”<br>Р.Вәлиева “Ашлар солтаны” | 2<br><br>1 | Икмәк,Тракторчы.комбайнчы<br>Машина йөртүче<br>Ашъяулык,бөккән,солтан |
| 8. Ашамлыклар | Ашамлыклар<br>Кунак чакырдык | 1<br>1 | Ашханә.пешече<br>Кыстап-кыстап,авыз итегез |
| | “Кафега барабыз” | 1 | |
| 9. Савыт-саба | Савыт-саба | 2 | Чәйнек.чәнечке.чынаяк.кәстрүл,кашык |
| | “Тәмле” кафесы ачабыз | 1 | |
| 10. Өй җиһазлары | Минем өем, өй җиһазлары | 1 | Урындык,өстәл,караватъ |
| | З.Туфайлова “Минем гаиләм” | 2 | бишек |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. Милли киемнәр | Әбиемнең серле сандыгы<br>Кием кешене бизи | 1<br>1 | Күлмәк.камзул.тәбәтәй.<br>Йөзек.беләзек<br>Алъяпкыч.читек.калфак |
| | “Күңелле уеннар” | 1 | |
| 12. Минем туган җирем | Татарстан буйлап сәяхәт<br>Туган ягым язучылары | 2<br>1 | Сәяхәт.шәһәр<br>Китап,язучы |
| 13. Башкалам - Казан | Башкалам - Казан<br>“Туган илем – туган өем”<br>Ә.Синегулова”Татарстан җирләре” | 1<br>1<br>1 | Башкала.мәчет. |
| 14. Кыргый хайваннар | Кыргый хайваннар<br>“Кыш.Тиеннәр” рәсеме | 1<br>1 | Бүре,төлке,аю,тиен<br>Койрык,соры |
| | “Циркта” | 1 | |
| 15. Ишек алдында | Авылда ишегалды<br>Йорт хайваннары.Ат белән колын. | 1<br>1 | Йон оек,йозак,бәйләнгән кофта<br>Ат,колын |
| | “Үрдәк беренчелекне алган” әкияте | 1 | Хәбәр,һөнәр |
| 16. Кыш килде | Кыш килде | 2 | Кыш.кар.буран. |
| | “Шаян кошлар” | 1 | Чана, шуа |
| 17. Кышкы уеннар | Кышкы уеннар<br>Яңа ел бәйрәме | 2<br>1 | Чана.шуа.җепшек.чаңгы.<br>Тимераяк.тау |
| | “Кар малай” мультфильмы | 1 | |
| 18 Кышлаучы кошлар | Кышлаучы кошлар<br>Кошларга ярдәм итик! | 2<br>2 | Күгәрчен.тукран.чыпчык<br>Песнәк.саескан.Җимлек. |
| | “Күңелле чыпчык белән күңелсез карга”әкияте | 1 | Күңелле,күңелсез |
| 19. Транспорт. | Юл йөрү кагыйдәләре | 2 | машинист |
| | Г.Юнысова “Светофор” | 1 | Озын агай |
| 20. Киемнәр | Киемнәр<br>Кышкы киемнәр | 1<br>1 | |
| | “Акбай туган көнгә барырга әзерләнә” | 1 | |
| 21. Муса Җәлил | Муса Җәлил | 1 | һәйкәл |
| | “Карак песи” | 1 | Дошман.чолан.карак<br>.тычкан.ак май. |
| 22. И туган тел, и матур | Бөтендөнья телләр көне | 1 | Туган тел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тел... | Дуслык-бөек көч | 2 | Дуслык,милләт |
| 23. Мин һәм минем сәламәтлегем | Сәламәтлек-зур байлык | 2 | Теш щеткасы,сөлге,мунчала,шапшак |
| 24. Ямьле яз | Ямьле яз<br><br>Яз.Сыерчыклар. | 2<br><br>1 | Яз.бөре.гөрләвек. Күк йөзе.һава торышы<br>Болытлы.кояәлы.<br>Бөре,кояш, |
| 25. Әкияттә кунакта | Әкияттә кунакта | 2 | А.Алиш,Г.Тукай әкиятләре буенча сүзлек |
| | “Теремкәй” әкияте | 1 | |
| 26. Күчмә кошлар | Күчмә кошлар | 2 | |
| | “Кем нәрсә ярата?” | 1 | |
| 27. Белем иленә сәяхәт | Белем иленә сәяхәт<br>Уку бүлмәсе | 2<br>2 | Мәктәп,каләм,китап,дәфтәр |
| | “Уйный-уйный укыйбыз” | 1 | |
| 28. Мәктәп | Без мәктәпкә барабыз | 2 | |
| | “Без инде хәзер зурлар - мәктәпкә илтә юллар” | 1 | Мәктәп,каләм,китап,дәфтәр |
| | “Юл маҗаралары” | 1 | |
| 29. Урман-безнең байлыгыбыз | Урманда<br>Нәрсә ул “Кызыл китап?” | 1<br>2 | |
| 30. Габдулла Тукай | Г. Тукай әкиятләренә сәяхәт<br>Без - Тукай оныклары | 2<br>1 | Шәкерт.әкият.шигырь. |
| | Г. Тукай “Шүрәле” | 1 | |
| 31. Әкияттә кунакта | «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>“Алтын бөртекләр”<br>«Агачлар да авырый» | 1<br>1<br>1 | Сандугач,алмагач<br>Бөртекләр<br>авырый |
| 32. һөнәрләр | Әти-әни һөнәре | 2 | Тегүче,сатучы,төзүче,китапханәче |
| 33. Без уйнарга яратабыз | Кибеттә<br>Мәктәптә<br>Балалар бакчасында | 1<br>1<br>1 | |
| 34. Җиңү бәйрәме | Алар безгә җиңү бүләк итте<br>Җиңү бәйрәме | 1<br>1 | Җиңү көне.батыр.тынычлык.<br>Бөек ватан сугышы. |
| 35. Хуш бакчам, исәнме | Кабатлау. | 1 | Кыңгырау.каләм.дәфтәр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| мәктәп | «Хуш бакчам, исәнме мәктәп» | 1 | Китап.акбур.мәктәп |
| | | 108 сәгать | |

**Эш төрләре һәм формалары**.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур.
Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

- Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
- Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
- Сюжетлы-рольле уеннар;
- Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
- Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
- Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
- Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
- Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
- Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
- Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
- Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
- Интерактив уеннар.

**Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (зурлар төркеме)**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор ( мәкаль, табышмак) | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомуми-ләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзен турында сөйләү | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |
| | Дамир | | | | | | | | | |
| | Алсу | | | | | | | | | |
| | ... | | | | | | | | | |

| Нәтиҗәләрне бәяләү | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>17-21 балл | Бала сөйләмдә актив, диалогта үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>12-16 балл | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1-11 балл | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (мәктәпкә әзерлек төркеме)**

<table>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2">Баланың исеме, фамилиясе</th><th colspan="3">Сүз байлыгы</th><th colspan="3">Бәйләнешле сөйләм</th><th rowspan="2">Фольклор ( мәкаль, санамыш, табышмак, әкиятләр)</th><th colspan="2">Нәтиҗә</th></tr>
<tr><th>Ягымлы сүзләр куллану</th><th>Сүзләрне гомуми-ләштерү</th><th>Капма-каршы сүзләр</th><th>Үзең турында сөйләү</th><th>Рәсем буенча сөйләү</th><th>Аралаша белү (диалог)</th><th>Баллар</th><th>Дәрәҗә</th></tr>
<tr><td></td><td>Алсу</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>Булат</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>...</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="11">Нәтиҗәләрне бәяләү</td></tr>
<tr><td colspan="3">Югары дәрәҗә<br>17-21 балл</td><td colspan="8">Бала сөйләмдә актив, диалогта үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Уртача дәрәҗә<br>12-16 балл</td><td colspan="8">Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1-11 балл</td><td colspan="8">Аңлый, русча җавап бирә.</td></tr>
</table>

## ТӘРБИЯЧЕЛӘР ӨЧЕН МЕТОДИК ЯРДӘМЛЕКЛӘР:

Зарипова З.М. «Татарча сөйләшәбез»  5-6  яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма.

Зарипова З.М. «Татарча сөйләшәбез» 6-7  яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма.

Зарипова З.М. «Туган телдә сөйләшәбез». 5-7 яшьлек балаларны ана теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма .

Зарипова З.М.”Үстерешле уеннар”. Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик кулланма.

Шаехова Р. К. «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы. Авазларны уйнатып. 1-2 кисәк». Тәрбиячеләр өчен методик кулланма.

Шаехова Р. К. «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы» тәрбиячеләр өчен.

Шаехова Р.К. Мәктәпкәчә белем бирү региональ программасы.

Закирова К.В. «Балачак аланы». Тәрбиячеләр һәм ата-аналар өчен хрестоматия.

Закирова К.В. «На поляне детства». Тәрбиячеләр һәм ата-аналар өчен хрестоматия.

Закирова К.В. «Балачак -  уйнап-көлеп үсәр чак». Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура  инструкторлары өчен методик ярдәмлек.

Закирова К.В. «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү ».

Кашапова М.Ф. «Уйныйк әле, балалар» методик  киңәшләр (беренче китап).

Ибраһимова З.Г. «Шома бас». Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татарча бию хәрәкәтләренә өйрәтү өчен  аудио-кушымтага методик кулланма.

**Әдәбият:**

1.Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның  17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган).

2.Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы.

3.Иванова Л. Ф. Программа обучения английскому языку в дошкольном образовательном учреждении Республики Татарстан “First Steps in English”. – Казань, 2011.

4.Гальперин П. Я.  “Основы теории поэтапного формирования умственных действий и концепции порождения речи”. -  Москва, 1989.

5.Пассов Е. И. “Основы коммуникативной методики обучения иноязычному общению”. -  Москва, 1989.

6.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү  программасы. «Идел-Пресс», 2013.

7.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2011

8.Зарипова З.М.,  Кидрячева Р.Г.  “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2012

9.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г.  “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Татарстан китап нәшрияты», 2012.

10.Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Әй, уйныйбыз, уйныйбыз”.- Казан, 2013.

11.Зарипова З.М., Исаева Р.С. “Үстерешле уен”.- Казан, 2013.

12.К. В. Закирова К.В., Муртазина Л.Р.  “Балачак – уйнап  - көлеп үсәр чак”.- Казан, 2012

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 0087A0B217414A40FE0BE3A1474CAE00E3
Владелец: Захарова Ольга Рудольфовна
Действителен: с 28.12.2023 до 22.03.2025